РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октябрь 2019г. г. Альметьевск №330

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында» 37 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 26 июлендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 228-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Коррупциягә каршы керәш турында» Федераль законның 13.1 статьясы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 3 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында» 37 нче карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 4 июлендәге 306 нчы номерлы, 2015 елның 13 мартындагы 455 нче номерлы, 2015 елның 10 декабрендәге 40 нчы номерлы, 2017 елның 27 июлендәге 191 нче номерлы, 2018 елның 11 маендагы 240 нчы номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 286 нчы номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 19 статьяда «Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр»:

1.1.1. 4.2 өлешендә «Җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи заты» сүзләреннән соң «яисә күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану» сүзләрен естәргә;

1.1.2. түбәндәге эчтәлекле 4.2-1 өлешен естәргә:

«4.2-1. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең үз керемнәре, чыгымнары, мелкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүмат биргән вазифаи затына, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында зур булмаган үзгәрешләр белән белешмәләр биргән өчен, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын аның вәкаләтләре вакыты туктатылганчы, район Советыннан, җирле үзидарәнең

Зак. № 3775

сайланулы органы вазифасыннан азат итү, район Советында, Җирле үзидарәнең сайланулы органында вазифа биләүдән мәхрүм итү;

3) вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан даими нигездә азат итү, вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү;

4) район Советында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре вакыты туктатылганчы вазифа биләүне тыю;

5) вәкаләтләре вакыты туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю»;

1.1.3. түбәндәге эчтәлекле 4.2-2 елешен өстәргә:

«4.2-2. Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затына, әлеге маддәнең 4.2-1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы «СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» Т.Д. Нагуманов